| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**14.12.2017** г. Казань
Казан шәһ. № 2669

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының аппаратында һәм территориаль органнарында дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалар урынына калу коррупция куркынычлары белән бәйләнгән, аларга билгеләү вакытында гражданнар һәм алар урынына калу вакытында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы булучы Вазыйфалар исемлеген раслау турында

2004 елның 27 июненнән № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законының 20, 20.1 статьяларына туры китереп, 2014 елның 23 июненнән № 460 «Керемнәр,чыгымнар турында, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында » Россия Федерациясе Президентының указына туры китереп б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының аппаратында һәм территориаль органнарында дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалар урынына калу коррупция куркынычлары белән бәйләнгән, аларга билгеләү вакытында гражданнар һәм алар урынына калу вакытында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы булучы Вазыйфалар исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).

2. 2014 елның 8 августыннан № 1449 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында алар урынына калу коррупция куркынычлары белән бәйле булган дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары исемлеген раслау турында» (2014 елның 25 августында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында

теркәлде, теркәү номеры 2400) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерык үтәлеше артыннан тикшерүне үземә калдырам.

Министр А.Ю.Вафин

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының
2017 елның 14 декабреннән № 2669
боерыгы белән расланга

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының аппаратында һәм территориаль органнарында дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары урынына калу коррупция куркынычлары белән бәйләнгән, аларга билгеләү вакытында гражданнар һәм алар урынына калу вакытында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә бурычлы булган Вазыйфалар исемлеге

1.«Җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр» (киңәшчеләр) категорияләр вазыйфаларының барлык төркемнәре чикләрендә 2006 елның 18 гыйнварыннан №УП-9 «Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары реестры турында» Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары реестрына кертелгән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары;
Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрының урынбасары;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының эшләр идарәчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының идарә башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бүлек башлыгы (идарә составына кермәүче);

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры ярдәмчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкче урынбасары;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкче урынбасары;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкче урынбасары – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының өлкән халыкка дәвалау һәм профилактик ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең балаларга медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру, бала тудыруга ярдәм итү хезмәте һәм демографик сәясәт бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең җитәкче урынбасары;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең дәвалау ярдәме бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһ. буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең икътисадый анализ һәм финанслау бүлеге башлыгы.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәтенең, алар урынына калу коррупция куркынычлары белән бәйле булган, башка вазыйфалары:

медицина эшчәнлегенең стандартларын һәм сыйфатын тикшерү идарәсенең медицина эшчәнлеге һәм медицина экспертизалары сыйфатын ведомствочылык тикшерү бүлеге башлыгы;

медицина эшчәнлегенең стандартларын һәм сыйфатын тикшерү идарәсенең стандартлар кертү һәм күзәтү бүлеге башлыгы;

медицина эшчәнлегенең стандартларын һәм сыйфатын тикшерү идарәсенең медицина белемен бирү һәм аттестацияләү бүлеге башлыгы;

дәвалау һәм профилактик ярдәм итү идарәсенең дәвалау ярдәме бүлеге башлыгы;

дәвалау һәм профилактик ярдәм итү идарәсенең балаларга медицина ярдәмен һәм бала тудыруга ярдәм итү хезмәтен оештыру бүлеге башлыгы;

дәвалау һәм профилактик ярдәм итү идарәсенең профилактик ярдәм һәм сәламәтлекне төзү бүлеге башлыгы;

дәвалау һәм профилактик ярдәм итү идарәсенең бюджет акчалары буенча икътисадый анализ бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һәм прогнозлау идарәсенең (мәҗбүри медицина иминияте) ММИ акчалары буенча икътисадый анализ бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һәм прогнозлау идарәсенең Дәүләт гарантияләре программасының исәпләү бүлеге башлыгы;

бюджеттан тыш сәламәтлек саклау секторының әйдәүче киңәшчесе;

фармация буенча идарәнең дарулар тәэминаты белән идарә итү бүлеге башлыгы;

фармация буенча идарәнең дарулар әйләнеше өлкәсендә тәртипкә салу бүлеге башлыгы;

фармация буенча идарәнең дәүләт заказын тәртипкә салу бүлеге башлыгы;

лицензияләү буенча идарәнең медицина эшчәнлеген лицензияләү буенча бүлеге башлыгы;

лицензияләү буенча идарәнең фармацевтик эшчәнлеген һәм наркотик матдәләр, психотропик матдәләр һәм прекурсорлар әйләнеше белән бәйле эшчәнлекне, наркотик матдәләр тәшкил иткән усемлекләрне үстерү буенча эшчәнлекне лицензияләү бүлеге башлыгы;

ведомство астында булучы учреждениеләрнең эшчәнлеген координацияләү һәм тикшерү секторының әйдәүче киңәшчесе.